РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ» ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2024 елның 21 ноябре** **Чистай шәһәре** **№36/4**

Физик затларны җир салымы
һәм мөлкәткә салым буенча
салым салудан азат итү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 56 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы нигезендә индустриаль (сәнәгать) паркларның җитештерү биналары һәм территорияләре инфраструктурасын үстерү һәм төзекләндерү, кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елга индустриаль (сәнәгать) парк буларак файдаланыла торган мөлкәткә һәм җир кишәрлекләренә карата Татарстан Республикасында индустриаль (сәнәгать) парк буларак дәүләт аккредитациясе алган кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасы субъектларын җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым салудан азат итәргә.
2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга .
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә (Н.В. Миңнегалиев) йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.И. Ксенофонтов